**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.03.2021** **№ 318**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 2411 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6.2 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында, аларны бетерү срокларын күрсәтеп һәм (яисә) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренә), Россия Федерациясе Музей фондларына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архивы фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зыян китерүне булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда

каралган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирергә;»;

2) 5.4. пунктта:

а) 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) әгәр язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә торган, кылынучы яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында белешмәләр, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында белешмәләр булса, шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш;»;

б 4) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) әгәр гражданның язма мөрәҗәгатендә элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә, асылы буенча аңа берничә тапкыр язма җаваплар бирелгән сорау булса һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат йә вәкаләтле зат, күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка юлланган очракта, әлеге мәсьәлә буенча чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгатьне җибәргән граждан хәбәр ителә.»;

3) 5.5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5.2.Шикаять үз эченә алырга тиеш:

-язма мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органының исеме, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яки тиешле затның вазыйфасы, шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәр итү, тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итә, шәхси имзасын һәм датаны куя.

- үз дәлилләрен раслауга кирәк булган очракта граждан язма мөрәҗәгатькә документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләрен кушымта итеп күрсәтә.

- җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә кушып бирергә хокуклы.».

4) 5.10. пункт

«5.10. Әлеге административ регламентның 5.9 пунктында күрсәтелгән кабул ителгән карар нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча һәм җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән тәкъдим, гариза яисә шикаятьне үз эченә алган билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез

затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибенең аңлатмасы белән, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләре үтәп, Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин